КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 15 сентябрь г.Казань № б-1838

Халыкка дәүләт сәясәте, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм мәдәни үсеше турында киң мәгълүмат бирү максатларында:

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына ведомство буйсынуындагы оешмалар (мәгариф оешмаларын, сәламәтлек саклау оешмаларын, мәдәният оешмаларын кертеп) өчен, аларның юнәлешен исәпкә алып, 2022 елның беренче ярты еллыгына вакытлы матбугат басмаларына, шул исәптән «Российская газета», «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан» иҗтимагыйсәяси газеталарына, «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы», «Казан утлары», «Татарстан» журналларына язылуны оештырырга һәм язылган басмалар санын 2021 елның беренче ярты еллыгына язылган басмалар саныннан ким булмаган күләмдә тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан 2022 елның беренче ярты еллыгына язылу кампаниясе барышын тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

2022 елның 30 гыйнварына кадәр язылу кампаниясе нәтиҗәләре турында Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына хисап җибәрүне;

«Российская газета» газетасы, район, шәһәр газеталары һәм республика журналлары, шул исәптән «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы», «Казан утлары», «Татарстан» журналлары редакцияләренә, «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» һәм «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениеләренә матбугат басмасын популярлаштыруга һәм аларга язылуны активлаштыруга булышлык итә торган чараларны үткәрүдә һәрьяклап ярдәм күрсәтүне.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе йөзендә «Россия почтасы» акционерлык җәмгыяте белән берлектә, 2022 елның 30 гыйнварына кадәр:

«Ачык Татарстан» порталында Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары яктылыгында 2022 елның беренче ярты еллыгына язылу кампаниясе йомгаклары турында мәгълүмат урнаштырырга;

2022 елның беренче ярты еллыгына вакытлы матбугат басмаларына язылу кампаниясе йомгаклары турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мәгълүмат кертергә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына язылу кампаниясен массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны оештырырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин